РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Глава
Урсаевского сельского поселения
Азнакаевского
муниципального района

ул. Центральная, д. 60,
Азнакаевский район, с.Урсаево,
423318,
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге
башлыгы

Үзәк ур., 60 нчы йорт, Азнакай
районы, Урсай авылы, 423318
тел./факс (885592)35-0-36
E-mail: Ursaev.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 29 » апрель 2022 ел** **№ 2**

Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге»
муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш
кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча
ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31нче маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль берәмлеге «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Азнакай муниципаль районы авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Урсай җирлеге Советының 18.02.2014 елнын 86 нчы номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча ачык тыңлаулар билгеләргә (2016 ел 30.01. 46 номерлы, 2017ел 04.09. 66 номерлы, 2019 ел 22.03.134 номерлы , 2020 ел 19.02. 170 номерлы , 2021 ел 17.08. 35 номерлы карарлар редакциясендә)

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү буенча ачык тыңлауларны оештыручы комиссияне;
- үткәрү вакыты - 2022 елның 04 маеннан 2022 елның 01 июненә кадәр 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;
- үткәрү урыны – Урсай авылы , Үзәк ур,60нчы йорт;
- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин булган адрес – Урсай авылы, Үзәк урам, 60 нчы йорт,Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә тәкъдим итәргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм билгеләнгән

тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән куллану кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проектын Интернет мәгълүмат-/телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru/.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru/.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык З.Х.Рахимьянова

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Урсай авыл җирлеге башлыгы
карарына 1 нче кушымта
29.04.2022 ел

**Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Урсай авылы "___ "_________2022 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Урсай җирлеге Советының 18.02.2014 елның 86 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында( 2016ел 30.01. 46 номерлы, 2017ел 04.09. 66 номерлы, 2019 ел 22.03.134 номерлы , 2020ел 19.02. 170 номерлы , 2021 ел 17.08. 35 номерлы карарлар редакциясендә)

Муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына туры китерү һәм 2021 елның 01 июлендәге 276-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» , 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2021 елның 30 апрелендәге 123-ФЗ номерлы «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законнар, «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» Федераль законның 1 статьясын һәм «Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турындагы нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе хакында» Россия Федерациясе Югары Советы карары үз көчен югалтуын тану һәм Россия Федерациясе закон актларының аерым нигезләмәләре» нигезендә

Урсай авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл Урсай җирлеге Советының 18.02.2014 елның 86 номерлы карары белән расланган, Татарстан

Республикасы Азнакай муниципаль районы «Урсай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә 2016ел 30.01. 46 номерлы, 2017ел 04.09. 66 номерлы, 2019 ел 22.03.134 номерлы , 2020ел 19.02. 170 номерлы , 2021 ел 17.08. 35 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 27 статьяның 5 пунктның 6 пунктчасына «, блокланган төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттә барлык йортларның да хокук ияләренең ризалыгы» сүзләрен өстәргә.

1.2. 27.1 статьяның 1 пунктында «Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү яисә реконструкцияләү максатларында» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортларны һәм күчемсез мөлкәтнең башка объектларын өлешле төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешле төзелештә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш» сүзләрен өстәргә.

1.3. 29 статьяның 3 пунктындагы 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын инженер-техник тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында акт (бу объектны мондый тоташтыру (технологик тоташтыру) проект документациясе тарафыннан каралган очракта);».

1.4. 36 статьяның 9 пунктында:

- өченче абзацта «эшләр башкару» сүзләрен « җир асты байлыкларыннан файдалану» сүзләренә алмаштырырга;

- алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Җир асты байлыкларының аерым участокларыннан файдалану ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалану һәм аларны саклау, әйләнә-тирә мохитне саклау максатларында чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Торак пунктлар һәм территорияләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану халыкның тормышы һәм сәламәтлеге иминлеге, әйләнә-тирә мохитне саклау куркынычы тудырырга, тау эшкәртмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның сакланышын да кертеп, биналарның һәм корылмаларның сакланышын булдырырга мөмкин булган очракларда чикләнергә яисә тыелырга мөмкин. Махсус сакланылучы табигать территорияләрендә җир асты байлыкларыннан файдалану аларның территорияләрен махсус саклау режимы нигезендә гамәлгә ашырыла. ("Җир асты байлыклары турында" законның 8 статьясы).

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Советының торак-коммуналь хуҗалык, төзекләндерү, экология һәм җир мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис З.Х.Рахимьянова